РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» ноября 2024 ел г. Альметьевск № 3701

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 24 декабрендәге 1915 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 24 декабрендәге 1915 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 736 номерлы) карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарда, карарның 1 нче кушымтасында һәм регламент кушымталарында:

муниципаль хезмәтнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирдән файдаланучы, җир биләүче җир кишәрлегенә хокуктан баш тартканда, җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану һәм җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату» тиешле килештә.

карарның 1 нче кушымтасында 1.3.2 пунктының 2) пунктчасында, 2.5.1 пунктының 3 һәм 1 пунктчаларында, 2.5.2 пунктының 2 пунктчасы, 2.5.3

пунктында, 2.7.1 пунктының 5 пунктчасында, 2.13.2 пунктында, 2.15.2 пунктының 9 абзацында, 2.16.1 пунктының б) һәм е) пунктчаларында, 2.16.2 пунктында, 2.16.3 пунктының д) пунктчасы, 2.16.4 пунктының 1 һәм 4 абзацларында, 3.2.3, 3.3.2 пунктларында, 3.6.3.2 пунктының 1 һәм 3 абзацларында, 3.7.1. пунктында:

«Республика порталының» сүзләрен «Бердәм, Республика порталының» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А. М. Каюмов